СОВЕТ СРЕДНЕКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.16А, с. Средние Кирмени, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422171

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КИРМӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ленин ур., 16А нчы йорт, Урта Кирмән авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422171

тел.(факс): (85563) 2-92-38;2-92-44 e-mail: Skimer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение | Карар

№ 1-34 | 17 сентябрь 2018 ел

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендәге 131 -ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елны, 28 июлендәге 45 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районыУрта Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 87,88,89 нчы статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районыУрта Кирмән авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советының 18.06.2018 ел, № 1-32 карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә.

2. Әлеге карарны закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3.Дәүләт теркәве узганнан соң, әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомумипринциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше, “Татарстан Республикасы Мамадыш

муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге” муниципаль берәмлегеУставының 89 статьясындагы 2 өлешенигезләмәләрен исәпкә алып, рәсмибасылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районыУрта Кирмән авыл җирлеге башлыгы Б.Ф.Хасановка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе Б.Ф.Хасанов

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы
Урта Кирмән авыл җирлеге Советының
17.09.2018 ел, _1-34 нчысанлы карарына
1 нчекушымта

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
Уставына кертелүче үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. 6 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 15 пункт өстәргә:

«15) «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру;.»;

2. «Гражданнар җыены» 23 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:1. Гражданнар җыены халык тарафыннан турыдан-туры җирлеүзидарәне гамәлгә ашыру һәм халыкның җирлеүзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуы формасы булып тора.

2. Гражданнар җыены «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда каралган очракларда һәм җирлек советы раслаган «Җирлек составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында» Нигезләмә нигезендә үткәрелә.

3. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясында каралган очракларда гражданнар җыены үткәрелергә мөмкин:

1) составына күрсәтелгән торак пункт кергән Җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча күрсәтелгән торак пункт территориясе башка җирлек (муниципаль район) территориясенәкертүне таләп итсә;

2) Җирлек Советы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә әлеге җирлекнең чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча;

3)Җирлек Советы вәкаләтләре гражданнар җыенын гамәлгә ашыра торган җирлектә, әгәр сайлау хокукына ия җирлектә яшәүчеләрнең саны җирлек Советы төзелү турындагы мәсьәлә буенча 100дән артык кеше тәшкил итсә, аның саны һәм вәкаләтләр чоры турында;

4)Җирлек Советы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

5) җирлек составына кергән торак пунктта, шәһәр эчендәге районда, федераль әһәмияттәге шәһәр эчендәге территориядә, шәһәр округында яисә муниципаль район чикләрендәге авылара территориядә урнашкан, әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

6) җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча халык инициативасын алга этәрү максатларында, авылара территориядә урнашкан торак пунктта;

7) авыл халкының урнашу тыгызлыгы түбән булган яисә начр юллы, бару авыр булган территориядә урнашкан җирлектә, әгәр авыл җирлеге халкының саны 100 кешедән артмаса, Җирлекне бетерү мәсьәләсе буенча;

8) авыл торак пунктында авыл торак пунктының старостасы кандидатурасын күрсәтү мәсьәләсе буенча, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча;

9) авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе составына кандидатуралар күрсәтү максатларында үткәрелергә мөмкин.

4. Гражданнарның җыены Җирлек башлыгы тарафыннан йә сайлау хокукына ия, кимендә 10 кеше яши торган торак пунктта яшәүчеләр төркеме инициативасы белән чакырылырга мөмкин.

5. Җыен үткәрү инициативасын хуплау йөзеннән җыелырга тиешле имзалар саны сайлау хокукына ия, торак пункт территориясендә даими яки нигездә яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санының 5 процентын тәшкил итә, ләкин 25тән дә ким була алмый.

6. Җирлек башлыгы чакыра торган халык җыены җирлек башлыгы карары белән билгеләнә, инициатив төркем тарафыннан чакырыла торган гражданнар җыены җирлек Советы карары белән билгеләнә.

7. Торак пункттаяшәүчеләргә халык җыенын үткәрү вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр итәләр, аларны муниципаль хокукый акт проекты һәм гражданнарҗыенын хәл итүгәчыгарыла торган мәсьәләләр буенча материаллар белән алданук «җирлексоставынакерүче торак пунктлардагражданнарҗыенынәзерләү тәртибе турында»нигезләмәдә билгеләнгән тәртип нигезендә танышатыралар.

8. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар булып торалар, җирлек башлыгы тарафыннан имзаланалар һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актларырегистрынакертелергә тиеш.

3. 50 статьяның 1 өлешендәге 5 пунктынтүбәндәге эчтәлекле 8 абзац өстәргә:

«Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыра.